Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Хатын белән мөгамәлә итү серләре

Икенче басма

Түбән Кама 2010

بسم الله الرحمن الرحيم

## Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده و نستعينه و نستغفره و نعوذ بالله من شرور أنفسنا و سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له و من يضلل فلا هادي له و أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له و أشهد أن محمدا عبده و رسوله، أما بعد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ юлы. Барча яңалык — бидгать, вә барча бидгать — адашу һәм барча адашу утка илтә.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلا تَمُوتُنَّ إِلا وَأَنْتُمْ مُسْلِمُونَ) آل عمران

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз. Аңа итагать итегез, каршылык вә гөнаһ кылмагыз. Аны зикер кылыгыз һәм онытмагыз. Аңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!».**

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ
مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا اللهَ الَّذِي
تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا) النساء: ١

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халикъ кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәмнең үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен сорагач кешенең кире какмаганлыгын беләсез. Шулай**

**булгач, Аллаһны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаһ бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».**

﴿يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللهَ وَقُولُوا قَوْلا سَدِيدًا يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَمَنْ يُطِعِ اللهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا﴾ الأحزاب: ٧٠-٧١

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка тәкъва булыгыз, вә хак булган файдалы, дөрес сүзләрне генә сөйләгез! Аллаһ әйткәнчә эш кылсагыз, Аллаһ эшләрегезне вә гамәлләрегезне төзәтер, вә гөнаһларыгызны ярлыкар. Берәү чын күңелдән Аллаһка, вә Аның расүленә итагать итсә, ул кеше һичшиксез өстенлеккә вә изге теләгенә ирешә».**

Дөреслектә, Аллаһ тәгалә Үзенең колларына өйләнүне билгеләде һәм кешеләр арасында бозыклык вә фәсәд булмасын өчен, аны гадәти күренеш кылды. Өйләнү ирләр һәм хатыннар өчен дә күңел тынычлыгы һәм зинадан саклану чарасы. Ир һәм хатын арасындагы бәхетнең вә шатлыкның хакыйкатькә чыгуын өстәп һәм дә алар арасындагы нәфрәт вә күңелсезлекләрне бетерүгә бер сәбәп булсын дип, ошбу язмаларны тәкъдим итәргә булдым. Без инде монда иң яхшы вә күркәм нәсыйхәтләрне генә җыярга тырыштык. Аллаһ Раббыбыз ошбу эшләребезне Үзенең ризалыгы өчен ихлас кылып, динебезгә файдалы гамәлләрдән әйләсә иде. Бу китапта булган аз гына тырышлык, хәерлесе вә дөресе Аллаһ тәгаләдән:

﴿وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُنْ تَعْلَمُ﴾ النساء: ١١٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ сиңа белмәгәнеңне өйрәтте».**

﴿وَلا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلا بِمَا شَاءَ﴾ البقرة: ٢٥٥

Мәгънәсе: **«Аллаһ гыйлеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ теләгәнне генә белерләр».**

Ә инде китапта хата вә кимчелек булса — минем үземнән вә шәйтаннан:

(قُلْ هُوَ مِنْ عِنْدِ أَنْفُسِكُمْ) آل عمران: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Бу үзегезнең нәфсегездән», — диген».**

(وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِلْإِنْسَانِ خَذُولا) الفرقان: ٢٩

Мәгънәсе: **«Шәйтан кешегә батылны матурлап вә хакны кабахәт кылып, алдап ташлап китәр булды».**

Аллаһ тәгалә барчабызга һидәят-тәуфикъ бирсен. Кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә насыйп итсен.

Я Раббым, безне Үзеңнең туры юлыңнан алып бар, хакны хак итеп белгерт һәм безне хаклыкка якынайт, батылны батыл итеп белгерт һәм безне батылдан ерагайт. Коръән вә Сөннәткә тотынучылардан кыл, һәм ихлас-тәкъва бәндәләреңнән әйләп, Үзеңнең рәхмәтең белән Фирдәвес Җәннәтләреңә керт. Әмин.

*Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи*

*Хатлар өчен:* ***mullaniyaz@mail.ru***

# ХАТЫН БЕЛӘН МӨГАМӘЛӘ ИТҮ СЕРЛӘРЕ

## Хатыныңны ничек сайлыйсың?

Изге-салиха хатын, тормышның иң гүзәл ләззәтедер. Шуңа да хатыныңны сайлауга бик тә игътибарлы бул! Әгәр дә син аңа карасаң — ул синең күңелеңне күтәрә, ә инде өйдә булмасаң — ул синең шәрәфеңне (намусыңны), мал-мөлкәтеңне һәм балаларыңны саклый.

(وَالَّذِينَ يَقُولُونَ رَبَّنَا هَبْ لَنَا مِنْ أَزْوَاجِنَا وَذُرِّيَّاتِنَا قُرَّةَ أَعْيُنٍ) الفرقان: ٧٤

Мәгънәсе: **«Алар әйтерләр: Әй Раббыбыз, безнең хатыннарыбызда вә балаларыбызда күзләребезгә вә күңелләребезгә тынычлык бир».**

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رضي الله عنه عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «تُنْكَحُ الْمَرْأَةُ لأَرْبَعٍ لِمَالِهَا وَلِحَسَبِهَا وَلِجَمَالِهَا وَلِدِينِهَا فَاظْفَرْ بِذَاتِ الدِّينِ تَرِبَتْ يَدَاكَ»

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатын-кызга дүрт нәрсә өчен өйләнәләр: байлыгы өчен, затлы нәселе өчен, чибәрлеге өчен һәм дине өчен. Диндар булганны сайла, югыйсә отыласың!»[1].***

Пәйгамбәребез ﷺ диндар булганны сайларга кушты, чөнки байлык бетә, затлы нәсел юкка чыга, чибәрлек вакыты белән туза вә таушала, ә инде дин — һәрвакыт кала.

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَمْرٍو أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «الدُّنْيَا مَتَاعٌ وَخَيْرُ مَتَاعِ الدُّنْيَا الْمَرْأَةُ الصَّالِحَةُ»

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дөнья ул — ләззәтлек, һәм андагы иң хәерле ләззәтлек — изге хатын»[2].***

Көннәрнең берендә Гомәр ؓ мөселманнарның хәл-әхвәлләрен белешеп урамда йөргәндә, кызына сөткә су кушарга боерган хатын-кызның тавышын ишетеп калды. Моңа җавап итеп бу кыз әнисенә: «Мөэминнәрнең әмире Гомәр ؓ сөтне су белән бутамаска кушты», — диде. Әнисе кызына: «Әй кызым! Безне бит Гомәр күрми», — дигәч, кызы: «Гомәр

---

1 Бухари (5090)
2 Мүслим (1467)

безне күрмәсә дә, безне Гомәрнең Раббысы күрә», — дип җавап бирде. Бу сүзләрне ишетеп торган Гомәр, бу кызның изгелеген вә диндарлыгын күреп, үзенең улы Гасыймны бу кызга өйләндерде һәм аларның киләчәк буыныннан Гомәр бин Габдулгазиз дөньяга килде.

## 🕮 Хатының өчен бизән вә зиннәтлән!

Хатының каршында һәрвакытта да матур вә күркәм бул! Ул синең өчен ничек зиннәтләнергә тырышса, син дә аның өчен шулай тырыш!

(وَلَهُنَّ مِثْلُ الَّذِي عَلَيْهِنَّ ) البقرة: ٢٢٨

Мәгънәсе: **«Хатыннарның ирләре каршында бурычлары булган кебек, шундый ук хокуклары да бар».**

Ибен Габбас ﵁ бу хакта: ***«Хатыным миңа ничек зиннәтләнә вә бизәнә торган булса, мин дә аның өчен шулай ук зиннәтләнәм вә бизәнәм»,*** — диде[3].

Шулай ук әсәрләрдә риваять ителгәнчә, дөреслеген Аллаһу әгъләм, болай диелде: ***«Зиннәтләнегез һәм пакьләнегез! Хакыйкатьтә, Бәнү Исраиль кавеменең ирләре пакьләнми вә зиннәтләнми иделәр һәм хатыннары зина кыла башладылар».***

Бервакыт Гомәр бин әл-Хәттаб ﵁ янына чәчләре тузгыган вә тузанга баткан бер ир, хатыны белән килеп керде һәм бу хатын Гомәргә: «Мин дә түгел, ул да түгел», — диде. Гомәр ﵁ бу хатын иреннән канәгать түгел икәнлеген белеп алды һәм ул иргә чәч-башын вә киемнәрен пакьләргә кушты. Ире матурланып вә зиннәтләнеп килгәч, хатыны канәгать вә риза икәнлеген белдерде.

---

3 «Мусаннаф» Ибен Әбий Шәйбәһ (19263)

Гомәр бин әл-Хәттаб ﵁ әйтә торган иде: ***«Кызларыгызны ямьсез ир-атка мәҗбүр кылмагыз, чөнки алар сез яратканны ук яраталар»[4].***

## 🕮 Хатыныңның туганнарына ихтирамлы бул!

Хатыныңның туганнарына ихтирамлы булу һәм кадер-хөрмәт күрсәтү, хатыныңа ихтирам күрсәтүнең бер өлешедер. Аның әтисен үзеңнең әтиең кебек үк хөрмәт ит, әнисен — әниең кебек хөрмәт ит, абый-энеләрен үзеңнең кардәшләрең кебек күр һәм башка туганнарын да шулай ук ихтирам ит! Шушы вакытта сезнең арадагы мәхәббәт дәвамлы булыр вә аның алдында синең кадерең үсәр.

Пәйгамбәребез ﷺ хатыннарының туганнарын күреп шатлана торган иде. Көннәрнең берендә аның янына Хәдиҗә радый Аллаһу ганһәнең апасы — Һәлә бинт Хуәйлид — керергә дип рөхсәт сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аны танып бик тә шатланды, чөнки ул аңа Хәдиҗәне хәтерләтте һәм: ***«Йә Аллаһ! Бу Һәлә бинт Хуәйлид»,*** — дип, шатлыгын белдерде[5].

***Хикәя:*** Риваятьләрдә килгәнчә, дөреслеген Аллаһу әгъләм, болай дип әйтелде: «Бер патша, фәкыйрь адәмнең диндар вә бик тә чибәр кызына өйләнә һәм хатынының әтисен күргән саен, аны кочаклап вә бик тә ягымлы итеп каршы ала торган була. Моны күреп патшаның вәзирләре: «Әй падишаһ! Син шундый дәрәҗәле була торып ничек инде ул фәкыйрьне хөрмәт итәсең?», — дип аптырашалар. Падишаһ вәзирләренә: «Мин ул кешене оныклары каршында хөрмәтлим вә кадерлим, әгәр моны оныклары күреп үссә, әти-әниләрен хөрмәтләрләр вә кадерләрләр», — дип җавап бирә.

4 «Мусаннаф» Габдурраззак (10339)
5 Мүслим (2437)

## 🕮 Хатыныңа елмаеп кара!

Хатыныңа елмаеп карасаң, бу караш аның йөрәгенә сары май кебек ятар. Шуңа да өеңә кергәндә, аны шатландырыр өчен, нәфис кенә елмаеп кер һәм дә өеңдә, хатыныңа вә балаларыңа йөз чытып төмсәләнүдән саклан!

Гаишә радый Аллаһу ганһәдән «Пәйгамбәребез ﷺ өенә кергәч ничек иде?», — дип соралгач, ул: ***«Ул (ﷺ) иң ягымлы, иң мөлаем вә елмаючан кеше иде»,*** — диде[6].

عَنْ عَبْدِ اللهِ بْنِ الْحَارِثِ قَالَ: «مَا رَأَيْتُ أَحَدًا أَكْثَرَ تَبَسُّمًا مِنْ رَسُولِ اللهِ»

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин әл-Хәрис ﷺ әйтте: ***«Мин пәйгамбәребездән дә (ﷺ) ешрак елмаючы кешене күрмәдем»[7].***

Шулай ук хикмәтле сүзләрдән: «Синең елмаюың, сиңа бернинди авырлык та китерми, ләкин ул елмаюың хатыныңны һәм балаларыңны шатландыра».

Бер хикмәт иясеннән: «Хатынымны ничек бәхетле итә алам?», — дип соралгач, ул: «Ягымлы карашың һәм татлы сүзең, синең хатыныңа алтын вә көмештән дә яхшырак», — диде».

## 🕮 Хатыныңа иң матур исемнәр белән дәш!

Хатыныңа һәрвакытта да, аның күңеленә ятышлы иң матур вә иң гүзәл исемнәр белән генә дәш! Аларга матур исемнәр белән дәшү, йорт эчендәге һаваны хушбуйландыра һәм күңелгә рәхәтлек бирә. Шуңа да, Аллаһ ризалыгы өчен тәмле телеңне дә, матур сүзеңне дә кызганма! Әгәр дә син аңа ***«матурым», «карлыгачым», «җан кисәгем», «кәбәм», «күз нурым»*** кебек һәм башка тылсымлы сүзләр белән дәшсәң, хатыныңның бу сүзләрдән юкә балы кебек эреп акканын күрерсең. Ха-

---

6 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр вә Зиядәһ» (9867) шәйх Әлбәний зәгыйфь диде

7 Тирмизи (3641) сахих

тыннарга карата мондый үслүб[8] куллану, пәйгамбәребезнең ﷺ үслүбе иде. Чөнки расүлебез ﷺ Гаишәнең күңеленә ягымлы булган исемнәр белән дәшеп: ***«Йә Гаиш!»,*** — дия торган иде[9], һәм шулай ук Гаишә радый Аллаһу ганһә бервакыт пәйгамбәребезгә: «Йә расүл Аллаһ! Минем барча якын әшнәләремнең[10] дә күньяләре[11] бар», — дигәч, пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Габдуллаһ[12] исеме белән күньялән»[13],*** — диде.

قال عمر بن الخطاب رضي الله عنه: «ثَلاث يصفين لك من وُدّ أخيك أن تسلم عليه إذا لقيت و توسع له في المجلس و تدعوه بأحب أسمائه إليه...»

Мәгънәсе: Гомәр бин әл-Хәттаб ﵁ әйтте: ***«Өч нәрсә, сиңа кардәшеңнең мәхәббәтен сафлый: Әгәр дә аны очратсаң — сәлам бирү, мәҗлестә аңа киң күңелле булу һәм аңа үзе яраткан исемнәр белән дәшү»[14].***

Шулай ук хикмәтле сүзләрдә вә мәкальләрдә: «Дустыңа матур исем белән дәшү, сиңа аның күңелен якынайта», — диелде.

## 🕮 Сезнең иң хәерлегез — гаиләсенә иң хәерле булганы!

Йортыңда һәрвакытта да гаиләңә карата иң хәерле, ягымлы, яратучы вә игелекле кешеләрдән булырга тырыш, чөнки хатын-кыз аерым мөгамәлә итүгә мохтаҗ.

---

8 урысча «метод» диелә

9 Бухари (3768)

10 дус, иптәш

11 Ата-анага баланың исеме белән дәшү, мәсәлән әгәр дә берәүнең Габдуллаһ исемле баласы булса аңа «Габдуллаһның әтисе», яки «Әбү Габдуллаһ», — дип әйтү, һәм шулай ук хатын–кызга да әйтелә.

12 Гаишәнең бертуган апасы Әсмәнең улы, чөнки ул Гаишәгә бик тә якын иде.

13 Әбү Дауыд (4970) сахих

14 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр вә Зиядәһ» (6319) шәйх Әлбәний зәгыйфь диде

(وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ فَإِنْ كَرِهْتُمُوهُنَّ فَعَسَى أَنْ تَكْرَهُوا
شَيْئًا وَيَجْعَلَ اللهُ فِيهِ خَيْرًا كَثِيرًا) النساء: ١٩

Мәгънәсе: **«Никахыгызда булган хатыннар белән яхшы мөгамәләдә булыгыз, гәрчә аларны бик яратмасагыз да, өметледер сез яратмаган нәрсәдә Аллаһның күп яхшылык кылмаклыгы».**

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «وَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا فَإِنَّ الْمَرْأَةَ خُلِقَتْ مِنْ ضِلَعٍ وَإِنَّ أَعْوَجَ شَيْءٍ فِي الضِّلَعِ أَعْلَاهُ فَإِنْ ذَهَبْتَ تُقِيمُهُ كَسَرْتَهُ وَإِنْ تَرَكْتَهُ لَمْ يَزَلْ أَعْوَجَ فَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا»

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Һәрвакытта да хатын-кызлар белән яхшы булыгыз, хакыйкатьтә, алар кабыргадан халык кылындылар, һәм андагы (кабыргадагы) иң кәкре урын — өске өлеше, әгәр дә син ул кабырганы турайтырга уйласаң — сындырырсың, ә инде аны калдырсаң, аңа тимәсәң — ул шулай ук кәкре булып калыр, (шуның өчен дә һәрвакытта да) хатын-кызлар белән яхшы булыгыз!»[15].***

عَنْ ابن عَبّاس رَضِي الله عَنْهُمَا عَنْ النَّبيّ ﷺ قَالَ: «خَيْرُكُمْ خَيْرُكُمْ لِلنِّسَاءِ»

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезнең иң хәерлеләрегез, хатын-кызларына карата яхшы булганы»[16].***

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «أَكْمَلُ الْمُؤْمِنِينَ إِيمَانًا أَحْسَنُهُمْ خُلُقًا وَخِيَارُكُمْ خِيَارُكُمْ لِنِسَائِهِمْ خلقا»

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Камил иманлы мөэминнәр шулардыр — кайсыларының холыклары иң яхшысы. Һәм сезнең арагызда иң хәерлеләре шулардыр — кайсылары хатын-кызларына иң яхшы холыклысы»[17].***

15 Бухари (3331)
16 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр вә Зиядәһ» (5627) шәйх Әлбәний сахих диде
17 Тирмизи (1162 хәсән сахих)

Шулай ук, Гали ؓ пәйгамбәребезнең ﷺ кызы — Фатыйманы — сорап килгәч, расүлебез ﷺ аңа: ***«Күркәм мөгамәлә итү шарты белән — ул сиңа»[18],*** — диде.

Әбү Дәрдә ؓ хатынына әйтә торган иде: «Әгәр дә минем ачуланганымны күрсәң — мине канәгатьләндер вә тынычландыр, ә инде мин синең ачуланганыңны күрсәм, мин сине канәгатьләндереп тынычландырырмын, югыйсә без бергә тормыш итә алмабыз!».

Хатын-кызларга карата яхшы мөгамәлә итү хакында Сәгалибий болай диде: «Кем үзенең гаиләсендә яхшы мөгамәлә белән сәясәтне алып бара торган булса, ул ир-ат барча кешеләр белән дә мөгамәлә итү сәясәтен алып баруга лаек!».

Бер хикмәт иясеннән берәү килеп: «Мин ничек иң хәерле кешеләрдән була алам?», — дип сорагач, ул аңа: «Әгәр дә син өеңдә хәерле ир була аласың икән, син хәерле кешеләрдән», — дип җавап бирде. Теге кеше моннан тагын: «Ничек мин өемдә хәерле ир-ат була алам?», — дигәч, ул: «Хатыныңа һәм балаларыңа күркәм холык белән», — диде.

## Хатыныңа ярдәм ит!

Йорт эшләрендә хатынга ярдәмләшүне күп кенә ирләр «ир-атны түбәнсетү» — дип, хаталы аңлыйлар. Бу инде түбәнсетү түгел, бәлки ярдәмләшү һәм ул рәхимлекнең бер төре. Шуңа да, пәйгамбәребез ﷺ үзенең йортында хатыннары белән нинди мөгамәләдә булса, син дә йортыңда хатыннарың белән шундый ук мөгамәлә дә булырга тырыш.

عَنِ الأَسْوَدِ بْنِ يَزِيدَ: سَأَلْتُ عَائِشَةَ رضى الله عنها «مَا كَانَ النَّبِىُّ ﷺ يَصْنَعُ فِى الْبَيْتِ؟» قَالَتْ: «كَانَ فِى مِهْنَةِ أَهْلِهِ فَإِذَا سَمِعَ الأَذَانَ خَرَجَ»

Мәгънәсе: Әсүәд бин Язид ؓ әйтте: «Мин Гаишә радый Аллаһу ганһәдән пәйгамбәребез ﷺ йортында нәрсә эшли иде дип сорагач, Гаишә миңа: ***«Ул йорт әһеленә ярдәмдә була***

18 «Силсиләһ әс-Сахихаһ» (166)

***иде, ә инде азанны ишеткәч (мәчеткә) чыгып китә иде»,*** — дип җавап бирде»[19].

Икенче риваятьтә: ***«Өс киемен тегә, аяк киемен төзәтә һәм барча ирләр дә өйләрендә эшләгәнне эшли»[20].***

Шулай ук Гомәр бин әл-Хәттаб ؓ Шәмдәге Хумс шәһәре әһелләре белән җыелганнан соң, Хумс кешеләре Гомәргә үзләренең әмирләре — Сәгыйд бин Гамирдән ؓ зарланып: «Ул безнең яныбызга төш вакыты җиткәч кенә чыга», — диделәр. Гомәр ؓ Сәгыйдтән ؓ моның сәбәбен сорагач, Сәгыйд бин Гамир ؓ: ***«Минем йорт әһелемнең бернинди хезмәтчеләре дә юк, шуңа да мин үзем камыр басам, аннары аның кабарганын көтәм, кабарып чыккач ипи пешерәм һәм шуннан соң гына таһәратләнеп (вуду алып) алар янына чыгам»,*** — дип җавап бирде.

## 🕮 Хатыннарың белән күңелле бул һәм уйна!

Хатыннар белән күңел ачу һәм уйнау, пәйгамбәребезнең ﷺ үслүбе[21] иде. Бу үслүб синең йортыңны яктыртучы шәмдәл кебек, бәхет вә шатлык чыганагының бер сәбәбе булып тора. Чөнки расүлебез ﷺ йорт әһелләре белән уйнап күңел ача иде.

عَنْ عَائِشَةَ رَضِيَ الله عَنْهَا قَالَتْ: أَتَيْتُ النَّبِيَّ ﷺ بِخَزِيرَةٍ قَدْ طَبَخْتُهَا لَهُ فَقُلْتُ لِسَوْدَةَ وَالنَّبِيُّ ﷺ بَيْنِي وَبَيْنَهَا: كُلِي، فَأَبَتْ، فَقُلْتُ: لَتَأْكُلِنَّ أَوْ لأُلَطِّخَنَّ وَجْهَكِ، فَأَبَتْ، فَوَضَعْتُ يَدِي فِي الْخَزِيرَةِ فَطَلَيْتُ وَجْهَهَا، فَضَحِكَ النَّبِيُّ ﷺ فَوَضَعَ بِيَدِهِ لَهَا وَقَالَ لَهَا: «الْطَخِي وَجْهَهَا»، فَفَعَلَتْ، فَضَحِكَ النَّبِيُّ ﷺ لَهَا ... ثم قال النبي ﷺ لهما: «قُومَا فَاغْسِلا وُجُوهَكُمَا» (أخرجه أبو يعلى (٤٤٩/٧ رقم ٤٤٧٦) وابن عساكر (٩٠/٤٤) قال الهيثمى (٣١٦/٤) رواه أبو يعلى ورجاله رجال الصحيح خلا محمد بن عمرو بن علقمة وحديثه حسن)

---

19 Бухари (5363)

20 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр вә Зиядәһ» (9068) сахих

21 Урысча «метод» диелә

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Бервакыт мин пәйгамбәребезгә ﷺ «хазира»[22] дип аталган ризык пешереп алып килдем. Пәйгамбәребез ﷺ Сәүдә бинт Зәмга[23] белән икебезнең арабызда иде һәм мин Сәүдәгә: «Аша», — дидем. Ул кире какты. Мин аңа: «Син ашаячаксың, яки мин синең йөзеңә ошбу ризыкны буяячакмын!», — дидем. Ул тагын кире какты,шуннан соң мин кулымны үзем пешергән ризыкка тыктым да, аның йөзен буядым. Пәйгамбәребез ﷺ моны күреп көлеп җибәрде һәм кулын аңа (Сәүдәгә) куйды да: ***«Син дә аның йөзен шулай ук буя!»,*** — диде. Сәүдә пәйгамбәребез ﷺ әйткәнчә эшләде. Моны күреп расүл ﷺ тагын көлеп җибәрде, шуннан соң аларга: ***«Торыгыз! Һәм битләрегезне юыгыз!»,*** — диде».

Шулай ук, икенче риваятьтә Гаишә радый Аллаһу ганһә пәйгамбәребезнең ﷺ хатыннары белән күңел ачуын бәян итеп болай диде: «Мин пәйгамбәребез ﷺ белән кайбер сәфәрләрендә бергә булганда, мин әле ул вакытта яшь кыз идем һәм минем тәнемә ит кунмаган иде, пәйгамбәребез ﷺ кешеләргә: ***«Бире килегез!»,*** — диде. Барчасы да килгәч расүлебез ﷺ миңа: ***«Бире кил! Хәзер мин синең белән узышам»,*** — диде. Без аның белән узыша башладык һәм мин аны уздым. Күпмедер вакытлар узып, минем тәнемә ит кунгач һәм миңа хатыннар төсе кергәч, шулай ук аның белән кайбер сәфәрләренә чыктым. Ул кешеләргә: ***«Бире килегез!»,*** — диде. Барчасы да килгәч расүлебез ﷺ миңа: ***«Бире кил! Хәзер мин синең белән узышам»,*** — диде. Без аның белән узыша башладык һәм ул мине узды. Шуннан соң расүлебез ﷺ елмаеп: ***«Бу узуым, элеккесе өчен»,*** — диде»[24].

---

22 Он, ит яки хайван мае һәм су кушылып пешерелгән шулпа

23 Пәйгамбәребезнең ﷺ икенче хатыны

24 Мүснәд Әхмәд (6\264) (шәйх Әлбәний сахих диде)

## 🕮 Хатыныңа матур сүзләр әйт һәм макта!

Хатын-кызлар мактаганны ярата. Шуңа да хатыныңның чибәрлеген, уңганлыгын, күркәмлеген, матур киенүен һәм башка нәрсәләрен искә алып, макта. Хатыннар, ирләренең мактавын ялган дип белсәләр дә, ләкин ул аларга бик тә ошый. Хәтта бу сүзләрең дөрес булмыйча ялган булса да, гаиләне ныгыту вә саклап калуда рөхсәт ителә.

قالت أُمُّ كُلْثُوم بِنْت عُقْبَة رَضي الله عَنْها: «وَلَمْ أَسْمَعْهُ يُرَخِّصُ في شَيْءٍ مِمَّا يَقُولُ النَّاسُ إِلاَّ فيِ ثَلاَثٍ، تَعْنِي: الحَرْبَ والإِصْلاَحَ بَيْنَ النَّاسِ وَحديثَ الرَّجُلِ امْرَأَتَهُ وَحديثَ المَرْأَةِ زَوْجَهَا»

Мәгънәсе: Үммү Күлсүм бинт Гукъбә радый Аллаһу ганһә әйтте: ***«Кешеләр сөйли торган нәрсәләрдән, пәйгамбәребез ﷺ өч нәрсәдә генә ялганны рөхсәт итте, ягъни: сугышта, кешеләрне килештерүдә һәм ир хатынына ә хатын иренә карата булган мөгамәләдә»***[25].

***Хикәя:*** «Бер ир бик тә чибәр хатынга өйләнә, ләкин ул хатынның чибәрлегендә бер кимчелек була. Аның колак яфраклары зур була. Күрше-тирә хатыннар моның чибәрлегеннән бик тә көнләшәләр икән һәм аны түбәнсетергә теләп, гел дә аның колак яфракларының зурлыгын искә алып ирештерә торган булалар. Бервакыт, бу хатын иренә ошбу хәлне сөйләп биргәч, ире инде хатынын юатырга теләп: «Матурым! Син инде моңа горурланырга гына тиеш», — дигәч, хатыны аңа: «Ничек инде мин колак яфракларымның зурлыгы белән горурланыйм?», — дип аптырап кала. Ире аңа: «Хикмәт ияләренең шундый сүзе бар: «Кемнең колак яфрагы зур булса, аның гомере озын була», — дип, хатынын тынычландыра. Хатыны аңа: «Мин инде беләм синең ялганлаганны, ләкин бу сүзләреңнән минем күңелгә рәхәт», — дип җавап бирә».

Шулай булгач, хатын-кыз үзенең чибәр булмаганлыгын белсә дә, ләкин иренең аны «чибәр» — дип, яки башкача мактавын ярата һәм өмет итә.

---

25 Бухари (2692), Мүслим (2605)

## 🕮 Хатыныңа бүләкләр бир!

Бүләк — хатыныңның күңелен вә йөрәген җәлеп итүгә иң уңайлы чараларның берсе булып тора. Әгәр дә гаилә тормышыңны шатлыклы вә бәхетле итәсең килә икән — хатыныңа бүләкләр яса! Пәйгамбәребез ﷺ безгә, бер-беребезгә карата мәхәббәт арттыруның сәбәпләрен аңлатып болай диде:

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «تَهَادَوْا تَحَابُّوا» (أَخْرَجَهُ الْبُخَارِيُّ فِي الْأَدَبِ الْمُفْرَدِ، حسن)

Мәгънәсе: ***«Бүләкләр бирегез, мәхәббәтле булырсыз».***

Шулай ук мәкальләрдә әйтелгәнчә: «Бүләк ул — ир белән хатын арасындагы мәхәббәт чарасы».

## 🕮 Йорт әһелләреңне шәргый бәйрәмнәр белән котла һәм шатландыр!

Йорт әһелләреңнең күңелләренә шатлык салу, гаиләне ныгытуга зур сәбәп булып тора. Шәрьгый бәйрәмнәрне үткәрүдә сүлпәнчелек булган йортта, хатының да, балаларың да тиешле рәвештә шатлык вә сәгадәт татый алмыйлар. Шуңа да, шәрьгый бәйрәмнәрне бәйрәм итүгә зур әһәмият бирергә кирәк.

عَنْ عَائِشَةَ رضى الله عنها قَالَتْ: دَخَلَ أَبُو بَكْرٍ وَعِنْدِى جَارِيَتَانِ مِنْ جَوَارِى الأَنْصَارِ تُغَنِّيَانِ بِمَا تَقَاوَلَتِ الأَنْصَارُ يَوْمَ بُعَاثَ، قَالَتْ: وَلَيْسَتَا بِمُغَنِّيَتَيْنِ، فَقَالَ أَبُو بَكْرٍ: أَمَزَامِيرُ الشَّيْطَانِ فِى بَيْتِ رَسُولِ اللَّهِ ﷺ؟! - وَذَلِكَ فِى يَوْمِ عِيدٍ. فَقَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «يَا أَبَا بَكْرٍ إِنَّ لِكُلِّ قَوْمٍ عِيدًا وَهَذَا عِيدُنَا»

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Бервакыт, гает көнне, минем йортта ансар кызларыннан, җырчы булмаган ике кыз «Бүгас»[26] хакында җыр җырлаганда Әбү Бәкер رضي الله عنه килеп керде һәм гаҗәпләнеп: «Ничек инде пәйгамбәребез

26 Мәдинәдән өч чакрым ераклыктагы урынның исеме. Бу җирдә, Исламга кадәр, Әус белән Хәзраҗ кабиләләре арасында бик тә каты сугыш булып, бик күп халык һәлак булды

ﷺ йортында шәйтан сыбызгысы булырга мөмкин?!», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Йә Әбү Бәкер! Һәрбер кавемнең үз гаете бар, һәм бу безнең гаетебез!»,*** — диде[27].

Шулай ук, Бухарида килгән икенче риваятьтә, гает көнне хәбәшиләр мәчеттә уйнаганда, пәйгамбәребез ﷺ Гаишәне шатландырырга теләп, аларның уйнаганнарын карап торырга рөхсәт итте.

Ошбулардан чыгып, гает көннәрендә йорт әһелләренең күңелләренә шатлык вә сәгадәт кертү тиешледер.

## Хатыныңны назла вә иркәлә!

Якынлык кылыр алдыннан хатыныңны назлау вә иркәләү, ул якынлык кылуның ләззәтенә китерә. Шуның өчен дә, якынлык кылуны үзең өчен генә ләззәт табу итеп, хатының өчен газап вә интегүгә әйләндермә!

Җәбир бин Габдуллаһ رضي الله عنه элек кияүдә булган хатынга өйләнгәч, пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Әгәр дә син яшь кызны иркәләсәң иде вә ул сине иркәләсә иде, һәм син аны елмайтып көлдерсәң иде вә ул сине елмайтып көлдерсә иде?!»,*** — диде[28].

Икенче риваятьтә пәйгамбәребез ﷺ болай диде:

«كُلّ شَيء لَيْسَ مِنْ ذِكْرِ اللهِ لَهْوٌ وَ لَعْبٌ إلاّ أَنْ يَكُونَ أَرْبَعَة: مُلاَعَبَة الرَّجُلِ امْرَأَتَهُ وَ تَأدِيب الرَّجُلِ فَرَسَهُ وَ مَشِي الرَّجُلِ بَيْنَ الْغَرَضَيْنِ وَ تَعْلِيم الرَّجُلِ السِّبَاحَة»

Мәгънәсе: ***«Аллаһны зикер итүгә кермәгән дүрт нәрсәдән башка, барча нәрсә дә — уен һәм файдасыз: Ир хатыны белән уйнау вә иркәләнү, атта чабу вә ат өйрәтү, (коралдан) атарга өйрәнү һәм йөзәргә өйрәнү»[29].***

27 Бухари (952)
28 Бухари (5367)
29 «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр вә Зиядәһ» (8663 сахих)

## 🕮 Хатыныңда артык шикләнүдән саклан!

Хатыныңның намуслы вә тугры булуында шикләнеп, шәйтан вәсвәсәсенә бирелмә! Бәлки аның хакында яхшы гына уйла, чөнки кирәкмәгән төрле уйлар вә шикләнүләр — гаилә тормышын гына боза.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اجْتَنِبُوا كَثِيرًا مِنَ الظَّنِّ إِنَّ بَعْضَ الظَّنِّ إِثْمٌ وَلَا تَجَسَّسُو) الحجرات: ١٢

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Күп гөманнан[30] саклanыгыз, тәхкыйк, кайбер гөман — гөнаһтыр. Вә кешеләрне күзәтмәгез вә гаепләрен эзләмәгез...».**

(وَالَّذِينَ يُؤْذُونَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ بِغَيْرِ مَا اكْتَسَبُوا فَقَدِ احْتَمَلُوا بُهْتَاناً وَإِثْماً مُبِيناً) الأحزاب: ٥٨

Мәгънәсе: «**Бернинди начарлыкны эшләмәгән мөэмин ирләрне вә мөэминә хатыннарны: «начарлыкны эшләдең», — дип хаксыз рәнҗетүчеләр, тәхкыйк үзләренә яла ягучы тамгасын һәм зур гөнаһны йөкләделәр».**

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِي الله عَنْهُ: أَنَّ رَسُولَ اللهِ صَلَّى الله عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «إِيَّاكُمْ والظَّنَّ فإِنَّ الظَّنَّ أَكْذَبُ الحَدِيثِ» (مُتَّفَقٌ عَلَيْهِ)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Гөманнан сакланыгыз! Хакыйкатьтә, гөман — иң ялган сүз!».***

## 🕮 Хатының белән ягымлы сөйләш һәм битәрләмә!

Ягымлы сөйләшү, барча мәшәкатьләрне чишүгә дә дәва булып тора. Сөйләшкәндә, гел дә аны гаепләп яки әүвәлге хаталарны искә төшереп сөйләшмә, бәлки хатының белән үзеңнең араңда булган һәр сөйләшүеңне, Аллаһ ризалыгы өчен, гаиләнең ныклы вә бәхетле булуына юнәлт. Ә инде

30 Уй, фикер, фараз, юрау

һәрбер кечкенә нәрсәгә хатыныңны битәрләү вә гел дә гаебен генә эзләп тору, бу инде гаиләнең бәхет учагын сүндерә. Мәхәббәт вә ягымлы сөйләшү белән йортыңда бәхәсләргә һәм гаугаларга урын калдырма!

Пәйгамбәребез ﷺ беркайчан да хатыннарын гаепләп яки әүвәлге хаталарын искә алып сөйләшмәде.

عَنْ عَائِشَةَ رِضِى الله عنها قَالَتْ: «قَالَ لِى رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «إِنِّى لأَعْلَمُ إِذَا كُنْتِ عَنِّي رَاضِيَةً وَإِذَا كُنْتِ عَلَيَّ غَضْبَى»، قَالَتْ: فَقُلْتُ مِنْ أَيْنَ تَعْرِفُ ذَلِك؟ فَقَالَ: «أَمَّا إِذَا كُنْتِ عَنِّى رَاضِيَةً فَإِنَّكِ تَقُولِينَ :لاَ وَرَبِّ مُحَمَّدٍ، وَإِذَا كُنْتِ غَضْبَى قُلْتِ: لاَ وَرَبِّ إِبْرَاهِيم»، قَالَتْ: قُلْتُ أَجَلْ وَاللَّهِ يَا رَسُولَ اللهِ مَا أَهْجُرُ إِلاَّ اسْمَكَ»

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ миңа: ***«Мин синең кайчан миннән риза булганыңны һәм кайчан миңа ачуланганыңны беләм»,*** — диде. Мин аннан: «Син моны каян беләсең?», — дип сорадым. Ул миңа: ***«Әгәр дә син миннән риза булсаң: «Мөхәммәднең Раббысы белән ант итәм», — дип әйтәсең, ә инде миңа ачулансаң: «Ибраһимның Раббысы белән ант итәм», — дисең»,*** — диде. Шуннан соң мин аңа: «Дөрес! Аллаһ белән ант итәм, йә расүл Аллаһ мин синең исемеңне генә үзгәртәм», — дидем»[31].

Пәйгамбәребез ﷺ белән Гаишә радый Аллаһ ганһә арасында булган бу сөйләшүдә, расүлебез ﷺ аны гаепләмичә вә битәрләмичә, матур һәм ягымлы итеп кенә сөйләште.

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِي الله عَنْهُ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «لا يَفْرَكْ مُؤْمِنٌ مُؤْمِنَةً إِنْ كَرِهَ مِنْهَا خُلُقًا رَضِيَ مِنْهَا آخَر»

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан رضي الله عنه: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин ир кеше мөэминәгә нәфрәтле (дошманлы) булмас, әгәр дә аның бер төрле холкын сөймәсә, башка холкыннан риза булыр»[32].***

***Булган хәл:*** «Бер егет белән бер кыз өйләнешүләренә күп тә үтми аерылыштылар. Бу кыздан: «Нигә аерылыштыгыз, өйләнешүегезгә ике-өч ай гына булды бит әле?», — дип со-

31 Бухари (5228)
32 Мүслим (1469)

ралгач, ул: «Ирем һәрбер нәрсәдә мине гаепли вә битәрли иде, әйтерсең дә ул миңа шуның өчен генә өйләнгән», — дип җавап бирде».

## 🕮 Хатының каршында булган бурычларыңны онытма!

Үзеңнең яраткан вә мавыккан әйберләрең белән генә булышып, хатының каршында булган бурычларыңны онытма, чөнки аның да синдә хакы бар. Хәзерге заманаларда кайбер ирләр үзләренең күңелләренә генә уңайлы нәрсәләр белән булышып (мәсәлән: компьютер, интернет, эш яки башка нәрсә), аларның өстендә хатыннарының хаклары барлыгын онытып җибәрәләр. Бу инде хатын-кызга карата золым кылу була. Чөнки ул ир, хатынына тиешле хакны, вакытны, башка нәрсәгә сарыф кылган булып чыга.

Пәйгамбәребезгә ﷺ хатыннарының хәл-әхвәлләрен белешеп, сөйләшеп һәм дә аларның мәшәкатьләрен чишеп торуга бернәрсә дә комачауламый иде.

عَنْ عَائِشَةَ رَضِي الله عَنْهَا قَالَتْ: «كَانَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ لاَ يُفَضِّلُ بَعْضَنَا عَلَى بَعْضٍ فِى الْقَسْمِ مِنْ مُكْثِهِ عِنْدَنَا وَكَانَ قَلَّ يَوْمٌ إِلاَّ وَهُوَ يَطُوفُ عَلَيْنَا جَمِيعًا فَيَدْنُو مِنْ كُلِّ امْرَأَةٍ مِنْ غَيْرِ مَسِيسٍ حَتَّى يَبْلُغَ إِلَى الَّتِى هُوَ يَوْمُهَا فَيَبِيتُ عِنْدَهَا»

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: ***«Расүлебез ﷺ беркайчан да (хатыннары арасындагы) көннәрне бүлүдә, беребезне икенчегә карата артыграк күрми иде. Һәркөнне ул безнең барыбызны да, тимичә генә (якынлык кылмыйча гына) йөреп чыга иде һәм кайсы хатынының көне булганына җитсә, шунда куна иде»***[33].

Шулай ук, Әнәстән ؓ килгән икенче риваятьтә әйтелгәнчә, пәйгамбәребезнең ﷺ тугыз хатыны бар иде һәм алар барысы да һәркөнне, пәйгамбәребез ﷺ кунасы хатынының йортында

33 Әбү Дауыд (2135) шәйх Әлбәний хәсән сахих диде

җыелалар иде. Расүлебез ﷺ аларның хәл-әхвәлләрен белешеп, сөйләшеп утыра торган иде[34].

## 🕮 Хатыныңның кимчелекләрен яшер!

Һәркемнең дә кимчелекләре бар. Әгәр дә сиңа, холкында яки үзендә кимчелеге булган хатын насыйп булды икән, аның кимчелекләрен башкаларга сөйләмә.

عن أَبِي هريرة رضي الله عنه عن النَّبيّ صلى الله عليه وسلم قَالَ: «مَنْ سَتَرَ مُسْلِماً سَتَرَهُ الله في الدُّنْيَا وَالآخِرَةِ»

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем мөселманның кимчелекләрен яшерә икән, Аллаһ тәгалә ул кешенең кимчелекләрен бу дөньяда да ахирәттә дә яшерер»[35].***

## 🕮 Хатыныңа сөйкемле вә мөлаем бул!

Сөйкемлелек вә мөлаемлык, ир һәм хатын тормышының хушбуедыр. Шуның өчен дә йортың бу сыйфатлардан буш булмасын. Пәйгамбәребез ﷺ хатыннарына карата бик тә мәхәббәтле вә мөлаем була торган иде.

قَالَتْ عَائِشَةُ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ ﷺ: «كُنْتُ لَكِ كَأَبِى زَرْعٍ لأُمِّ زَرْعٍ»

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһәдән: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мин синең өчен, Әбү Зәргь Үммү Зәргька[36] (сөйкемле) булган кебек булдым»[37].***

Шулай ук икенче риваятьтә Гаишә радый Аллаһу ганһә болай дип хәбәр итте: ***«Бервакыт минем хайд вакытымда,***

34 Муслим (1462)

35 Муслим (2699)

36 Әбү Зәргь белән Үммү Зәргьның кыйссасы, хәдисләрдә билгеле кыйсса. Бу кыйссада ир белән хатынның яхшы мөгамәләтләре чагылдырыла

37 Бухари (5189)

***сөяктән ит ашаганда пәйгамбәребез дә үзенең авызын минем ашаган урынга куйды, һәм мин эчкәндә, ул да авызын минем эчкән урынга куйды»,*** — диде[38].

Расүлебез ﷺ хәтта ураза хәлендә дә хатыннарына ягымлы булуны калдырмады. Үммү Сәләмәһ әйтүенчә, пәйгамбәребез ﷺ ураза хәлендә хатыннарын үбә торган иде[39].

## 🕮 Хатының белән киңәшләш!

Гаилә тормышын бергә алып баруда хатыныңны читләштермә. Үзегезнең тормышыгызны алып баруда килеп чыккан авырлыкларда аның белән киңәшләш һәм аның бу мәсьәләгә карата карашын сора. Бу киңәшләшүләр хатыныңның күңелен күтәрә һәм араларны яхшырта.

(وَأَمْرُهُمْ شُورَى بَيْنَهُمْ) الشورى: ٣٨

Мәгънәсе: **«Вә кирәк булганда үзара киңәш итәрләр».**

Пәйгамбәребез ﷺ үзенең хатыннары белән киңәшләшә торган иде һәм аларның фикерләрен сорый иде. Моңа мисал итеп, расүлебезнең ﷺ "Худәйбия солыхы"нда булган вакыйганы китерергә була.

"Хүдәйбия солыхы"нда пәйгамбәребез ﷺ килешү язмасы беткәннән соң, сахәбәләренә: ***«Торыгыз һәм корбаннарыгызны чалып, чәчләрегезне кырыгыз!»,*** — диде. Пәйгамбәребез ﷺ өч тапкыр кабатлап әйтүгә карамастан, беркем дә кузгалмады. Шуннан соң расүлебез ﷺ хатыны — Үммү Сәләмәһ — янына керде һәм кешеләрдән очраткан ошбу хәлне сөйләп бирде. Үммү Сәләмәһ пәйгамбәребезгә ﷺ: «Йә расүл Аллаһ! Син әмереңнең үтәлүен телисеңме? Син чык та, үзеңнең корбаныңны чалып һәм чәч кыручыңны чакыртып,ул синең чәчеңне кырганчыга кадәр, һичкемгә дә берсүз дә әйтмә!», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ чыкты да, үммү Сәләмәһ

---

38 Нәсәи (70) сахих
39 Бухари (1929)

әйткәнчә эшләде. Бу хәлне күреп сахәбәләр дә корбаннарын чалдылар һәм ашыга-ашыга чәчләрен кыра башладылар[40].

## 🕮 Хатыныңнан гаеп эзләмә!

Гаилә тормышы төрле хаталар вә ялгышлыклар белән тулы. Шуның өчен дә, хатыныңнан гел гаеп вә хаталар гына эзли торган кеше кебек булма, ә бәлки киң күңелле бул!

عَنْ جَابِرٍ رضي الله عنه قَالَ: «نَهَى رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم أَنْ يَطْرُقَ الرَّجُلُ أَهْلَهُ لَيْلاً يَتَخَوَّنُهُمْ أَوْ يَلْتَمِسُ عَثَرَاتِهِمْ»

Мәгънәсе: Җәбир бин Габдуллаһтан ﵁: ***«Пәйгамбәребез ﷺ ир кешегә, үзенең хатынында хыянәт яки хыянәткә бәйле нинди дә булса гаеп табырга тырышып, төнлә белән кайтуны тыйды»[41].***

***Хикәя:*** Бер гыйлем иясе, бик тә чибәр, әмма ләкин томана булган бер авыл кызына өйләнә. Көннәрнең берсендә бу гыйлем иясе язу-сызу эшләре белән шөгыльләнеп утырганда, хатыны өстәлдәге тузаннарны сөртәм дип, ялгыш иренең язмаларын туздыра һәм моңа бик тә борчылып елый башлый. Ире хатынын кызганып: «Кайгырма матурым, ул кәгазьләрнең таралуына мин үзем гаепле, чөнки уңайсызрак урынга куйганмын мин аларны», — дип хатынын тынычландыра. Бераздан соң хатыны ире яныннан узып киткәндә, тегенең кара савытын төшереп вата. Ире аңа: «Әлхәмдүлилләһ! Мин инде күптән яңа кара савыты алырга ниятләгән идем», — дип хатынын юата. Күпмедер вакыттан соң ире намазга дип таһәрат ала башлый. Хатыны чәй кайнатырга дип чәйнеккә су алам дигәндә, ялгыш чәйнекне иренең башына төшереп җибәреп, тегесенең башын тишә һәм иренең башыннан кан агып чыга. Хатыны нишләргә белмичә югалып кала вә үксеп-үксеп елый башлый. Ире аңа: «Әлхәмдүлилләһ! Бернинди зарар да юк матурым, мин инде

---

40 Бухари (2731, 2732)
41 Мүслим (715)

болай да хиҗәмә[42] ясатмакчы идем, син минем акчаны да, вакытны да сакларга сәбәп кенә булдың», — дип хатынын тынычландыра, һәм: «Минем йортым — минем кечкенә дәүләтем, мин аны вак-төяк сәбәпләр аркасында гаеп табып җимерергә җыенмыйм», — ди.

## 🕮 Хатыныңны юат!

Хатыныңның күз яшьләрен ягымлы сүзләр белән сөрт һәм аңа авыр булган вакытта — янында бул! Аны кайгы яки борчу басканда, синең ягымлы сүзләрең аның күңеленә шифалы су кебек булсын һәм пәйгамбәребез ﷺ хатыннарына ничек булса, син дә шулай бул!

عَنْ أَنَس قَالَ: بَلَغَ صَفِيَّةَ أَنَّ حَفصَةَ قَالَتْ بِنْتُ يَهُودِيٍّ، فَبَكَتْ فَدَخَلَ عَلَيْهَا النَّبِىُّ ﷺ وَهِىَ تَبْكِى فَقَالَ: «مَا يُبْكِيكِ؟» فَقَالَتْ: قَالَتْ لِى حَفْصَةُ إِنِّى بِنْتُ يَهُودِيٍّ، فَقَالَ النَّبِىُّ صلى الله عليه وسلم: «إِنَّكِ لَابْنَةُ نَبِيٍّ وَإِنَّ عَمَّكِ لَنَبِىٌّ وَإِنَّكِ لَتَحْتَ نَبِيٍّ فَفِيمَ تَفْخَرُ عَلَيْكِ؟» ثُمَّ قَالَ: «اتَّقِى اللَّهَ يَا حَفْصَةُ»

Мәгънәсе: Әнәс رضي الله عنه әйтте: «Сафиягә[43] Хафсаның[44] «Син яһүд кызы» — дигән сүзләре ирешкәч, Сафия елый башлады. Пәйгамбәребез ﷺ аның елап утырганын күреп: ***«Нигә елыйсың?»,*** — дип сорады. Сафия: «Хафса мине: «Син яһүд кызы», — дип битәрли», — диде. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Дөреслектә, син пәйгамбәр кызларыннан, синең бабаң пәйгамбәр иде һәм син үзең дә пәйгамбәр хатынысың. Ул (Хафса) нәрсәсе белән үзен синнән артык саный!?»,*** — диде. Шуннан соң расүлебез ﷺ Хафсага: ***«Аллаһка тәкъвалы бул, йә Хафса!»,*** — диде»[45].

Пәйгамбәребез ﷺ Сафияне ягымлы сүз белән юатып, күңелен күтәрде.

---

42 Шәригатебездә билгеле булган кан алдыру ысулы

43 Пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны

44 Пәйгамбәребезнең ﷺ хатыны

45 Тирмизи (3894 сахих)

## Гаилә тормышы сине гыйбадәттән читләштермәсен!

Хатыннарың һәм балаларың, сиңа гыйбадәттә һәм савап җыюда киртә булмасыннар!

Хәнзаләһ бин Әбү Гамир ﵁ «Үхүд» сугышында вафат булгач, пәйгамбәребез ﷺ аның хакында: ***«Хакыйкатьтә, сезнең кардәшегезне (Хәнзаләһне) фәрештәләр госел коендыра, аның иптәшеннән сорагыз»,*** — диде. Хәнзаләһнең хатынынннан сорадылар, һәм ул: «Хәнзаләһ җөнеб иде, җиһәдкә чакыруны ишетү белән госел дә коенып тормыйча чыгып чапты», — диде. Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ: ***«Шуның өчен аны фәрештәләр госел коендыра»,*** — диде[46].

Габдуллаһ бин Әбү Бәкер ﵁ Гатикә бинт Зәйдкә өйләнгәч, хатынының чибәрлеге вә сөйкемлелеге аркасында җиһәдләрне калдыра башлады. Бу хәлне Әбү Бәкер ﵁ белеп алып, улы Габдуллаһка: «Хатыныңны артык яратуың сиңа җиһәдләрне калдыруга сәбәпчел, аны талак кыл!», — дип, хатынын аерырга кушты. Габдуллаһ Гатикәне аерып җибәрде. Күпмедер вакыт узгач, Әбү Бәкер, улы Габдуллаһка, Гатикәне кайтарырга кушты һәм Габдуллаһ аны кайтарып алды. Шуннан соң, Габдуллаһ бин Әбү Бәкер пәйгамбәребез ﷺ белән Таиф газаватына[47] чыкты һәм анда ук тиеп яраланганнан соң, Мәдинәгә кайткач бераздан соң вафат булды[48].

## Хатыннарың арасында гадел бул!

Гаделлек — гаилә тормышының шәмдәле һәм ир белән хатын арасына өлфәт вә мәхәббәт сибүче нур кебектер.

(فَانْكِحُوا مَا طَابَ لَكُمْ مِنَ النِّسَاءِ مَثْنَى وَثُلَاثَ وَرُبَاعَ
فَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا تَعْدِلُوا فَوَاحِدَةً) النساء: ٣

46 «Сүнән әл-Бәйһәкый» (7062) хәсән

47 Пәйгамбәребез ﷺ катнашында Таиф шәһәренә каршы булган сугыш

48 «Җәмигъ әл-Әхәдис» әс-Суютый (27814)

Мәгънәсе: **«Күңелегезгә хуш килгән хатыннарны үзегезгә никах кылып алыгыз: икешәр, өчәр һәм дүртәрне, әгәр дә инде гаделлек кыла алмабыз дип курыксагыз, фәкать берне генә никахлагыз».**

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنِ النَّبِيِّ ﷺ قَالَ: «مَنْ كَانَ لَهُ امْرَأَتَانِ يَمِيلُ لِإِحْدَاهُمَا عَلَى الأُخْرَى جَاءَ يَوْمَ الْقِيَامَةِ أَحَدُ شِقَّيْهِ مَائِلٌ»

Пәйгамбәребез ﷺ хатыннар арасында гаделлеккә өндәп болай диде, мәгънәсе: ***«Кемнең ике хатыны булып берсен икенчесенә караганда өстенрәк күрә икән, Кыямәт көнендә бер ягы кыегайган хәлдә кубарылыр»[49].***

عَنْ عَائِشَةَ قَالَتْ: كَانَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَقْسِمُ فَيَعْدِلُ وَيَقُولُ: «اللَّهُمَّ هَذَا قَسْمِي فِيمَا أَمْلِكُ فَلا تَلُمْنِي فِيمَا تَمْلِكُ وَلا أَمْلِكُ» (ابن ماجه ١٩٧١، تحقيق الألباني: ضعيف، لكن الطرف الأول منه حسن)

Расүлебез ﷺ хатыннары арасында гаделлекне саклый иде, һәм бу хакта Гаишә радый Аллаһу ганһә болай диде: «Расүл ﷺ хатыннары араларын тигез итеп һәм гаделлек белән бүлә иде, һәм: ***«Йә Аллаһ! Бу минем көчемнән булган тигезлек вә гаделлек, минем көчемнән булмаган, Үзеңнең кодрәтеңнән булган (йөрәкнең кемгә дә булса авышуы) өчен, мине битәрләмә»,*** — дип әйтә иде».

عَنْ عَائِشَةَ رضي الله عنها: «أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم كَانَ إِذَا سَافَرَ أَقْرَعَ بَيْنَ نِسَائِهِ» (ابن ماجه ١٩٧٠، تحقيق الألباني: صحيح)

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: ***«Расүлебез ﷺ сәфәргә чыга торган булса, хатыннары арасында шобага сала иде».***

Пәйгамбәребез ﷺ хәтта авырган вакытта да хатыннары арасында гаделлекне сакларга тырыша иде, һәм: «Мин бүген кемдә? Мин иртәгә кемдә?», — дип, сорый торган иде[50].

Хикмәтле сүзләрдә: «Гаделлек булмаган йорт — кечкенә зиндан», — дип әйтелде.

Мүгаз бин Җәбәлнең ؓ ике хатыны бар иде. Әгәр дә берсенең көне булса, ул икенче хатынында таһәрат тә алмый, хәтта су

49 Нәсәи (3942 сахих)

50 Бухари (1389)

да эчми иде. Шәм илләрендә тагун[51] чире таралган елларда, аның ике хатыны да бер көнне вафат булдылар. Кешеләр барчасы да мәшгуль булу сәбәпле, ул үзе кабер казыды да һәм кайсысын алданрак каберга төшерү өчен араларына шобага салды.

## 🕮 Хатыныңның холык-фигылен көч белән үзгәртәм димә!

Көч белән хатын-кызның холкын үзгәртү, ике арадагы мәхәббәтне генә үтерә. Шуның өчен дә бу гамәлдән саклан!

(فَبِمَا رَحْمَةٍ مِنَ اللَّهِ لِنْتَ لَهُمْ وَلَوْ كُنْتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ
لَانْفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ) آل عمران: ١٥٩

Мәгънәсе: **«Аллаһның рәхмәте белән син аларга (сахәбәләреңә) шәфкатьле булдың, әгәр дә син аларга тупас вә каты бәгырьле булсаң, әлбәттә, алар синең тирәңнән качар иделәр».**

(وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِلْعَالَمِينَ) الأنبياء: ١٠٧

Мәгънәсе: **«Без сине, мәгәр галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек».**

عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «وَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا فَإِنَّ الْمَرْأَةَ خُلِقَتْ مِنْ ضِلَعٍ وَإِنَّ أَعْوَجَ شَيْءٍ فِي الضِّلَعِ أَعْلَاهُ فَإِنْ ذَهَبْتَ تُقِيمُهُ كَسَرْتَهُ وَإِنْ تَرَكْتَهُ لَمْ يَزَلْ أَعْوَجَ فَاسْتَوْصُوا بِالنِّسَاءِ خَيْرًا» (البخاري ٣٣٣١)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Һәрвакытта да хатын-кызлар белән яхшы булыгыз, хакыйкатьтә, алар кабыргадан халык кылындылар, һәм андагы (кабыргадагы) иң кәкре урын — өске өлеше, әгәр дә син ул кабырганы турайтырга уйласаң — сындырырсың, ә инде аны калдырсаң, аңа тимәсәң — ул шулай ук кәкре булып калыр, (шуның өчен дә һәрвакытта да) хатын-кызлар белән яхшы булыгыз!».***

51 Урысча «чума» диелә

## 🕮 Хатыныңа кул күтәрмә!

Беркайчан да хатыныңа каты итеп сукма, чөнки аңа кул күтәрү, аерылышуга вә талакка сәбәп булып тора. Хатыннарны тәрбияләү йөзеннән, сугу шәргый сәбәп буенча рөхсәт ителсә дә, ләкин ул җиңелчә генә булырга тиеш, ә инде сугудан читләшү — хәерлерәк санала.

عَنْ عَائِشَةَ رضي الله عنها قَالَتْ: «مَا ضَرَبَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم شَيْئًا قَطُّ بِيَدِهِ وَلاَ امْرَأَةً وَلاَ خَادِمًا إِلاَّ أَنْ يُجَاهِدَ فِى سَبِيلِ اللَّهِ...»

Мәгънәсе: Гаишә радый Аллаһу ганһә әйтте: ***«Расүлебез ﷺ кулы белән беркайчан да, беркемгә дә — хатын-кызга да, хезмәтчегә дә — сукмады, иллә мәгәр Аллаһ юлында җиһәд кылганда гына...»[52].***

Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ, хатыннарына сәбәпсез кул күтәрүчеләрне шелтәләп: ***«Сезнең кайберүләрегез хатыннарына, колларга суккан кебек суга, ә аннары, бәлки, ул көн ахырында (кич белән) хатыны белән йокларга да ята»[53],*** — диде.

Икенче хәдистә, кыскача мәгънәсе: ***«Аллаһның коллары булган хатын-кызларга — сукмагыз!»,*** — диде[54].

## 🕮 Хатыныңны гыйлемгә өйрәт!

Ана — балаларның тәрбия мәдрәсәсе булып тора, шуның өчен дә хатыныңны шәрьгый гыйлемгә өйрәт! Чөнки, гаиләңнең ничек тәрбияләнүенә иң беренче булып син җаваплы. Бу хакта пәйгамбәребез ﷺ болай дип әйтеп узды, мәгънәсе: ***«Сез һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үзенең көтүенә җаваплы...»[55].***

Икенче риваятьтә: ***«Өч төрле кешегә икеләтә әҗер-савап булыр (һәм шуларның берсе): Әгәр дә бер ир-атның***

52 Мүслим (2328)
53 Бухари (4942), Мүслим (2855)
54 Әбү Дауыд (2146)
55 Бухари (893), Мүслим (1829)

***хатын-кыз колы булып, ул аны яхшы итеп тәрбияләп һәм гыйлем биреп азат иткәннән соң, ул хатынга өйләнсә, аңа икеләтә әҗер-савап булыр»,*** — диде[56].

Шулай ук, кайбер әсәрләрдә[57] риваять ителгәнчә, дөреслеген Аллаһу әгъләм, болай диелде: «Кыямәт көнендә ир-ат беренчеләрдән булып хатыны һәм балалары хакында соралыр һәм алар әйтерләр: «Йә Раббыбыз! Безнең өчен аңа тиешле җәзасын бир! Хакыйкатьтә, ул безгә белмәгәнебезне өйрәтмәде һәм безгә хәрам ризыклар ашатты, без аларның хәрам икәнлеген белми идек».

Әл-Гыйрбәдъ бин Сәрияһ ؓ әйтте: «Мин пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишеттем: ***«Кем дә кем хатынын су эчертә икән, ул әҗер-савапка иреште»,*** — диде. Шуннан соң мин кайттым да, хатынымны су эчерттем һәм расүлебездән ﷺ ишеткәнне аңа да сөйләдем». (Мүснәд Әхмәд)

## Хатыныңны ата-анаңнан артык күрмә!

Хатыныңны бик яратсаң да һәм бик якын итсәң дә, аны ата-анаңнан артык күрмә! Бу хакта аятьләр вә хәдисләр бихисап.

(وَقَضَى رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا) الإسراء: ٢٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә».**

عنِ أَبي هريرة رضي الله عنه قَال: جاء رجل إِلَى رَسُول الله صلى الله عليه وسلم فَقَالَ: يَا رَسُولِ الله مَنْ أَحَقُّ النَّاسِ بِحُسْنِ صَحَابَتِي؟ قَالَ: «أُمُّكَ» قَالَ: ثُمَّ مَنْ؟ قَالَ: «أُمُّكَ» قَالَ: ثُمَّ مَنْ؟ قَالَ: «أُمُّك» قَالَ: ثُمَّ مَنْ؟ قَالَ: «أَبُوكَ» (مُتَّفَقٌ عَلَيهِ)

Мәгънәсе: Әбү Һүрайра ؓ әйтте: «Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ янына бер кеше килде дә: «Әй расүл Аллаһ! Мин яхшы мөнәсәбәт тотуга кешеләрнең кайсысы лаеклырак?» — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Синең анаң»,*** — диде. (Бу

56 Бухари (97)
57 «Ихья гулүм әд-дин» Әбү Хәмид әл-Газәли

кеше): «Ә аннан соң кем?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Синең анаң»,*** — диде. (Бу кеше): «Ә аннан соң кем?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Синең анаң»,*** — диде. (Бу кеше янә): «Ә аннан соң кем?», — дип сорады, һәм шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Синең атаң»,*** — дип әйтте».

عن عبد الله بنِ مسعود رضي الله عنه قَالَ: سألت النَّبيّ صلى الله عليه وسلم: أيُّ العَمَلِ أحَبُّ إِلى اللهِ تَعَالى؟ قال: «الصَّلاةُ عَلَى وَقْتِهَا» قُلْتُ: ثُمَّ أي؟ قَالَ: «بِرُّ الوَالِدَيْنِ» قُلْتُ: ثُمَّ أيٌّ؟ قَالَ: «الجِهَادُ في سبيلِ الله» (مُتَّفَقٌ عَلَيه)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуд ؓ әйтте: «Бервакыт мин пәйгамбәребездән ﷺ: «Аллаһ нинди эшне барысыннан да күбрәк ярата?» — дип сорадым. Ул: ***«Вакытында укылган намаз»,*** — дип җавап бирде. Мин: «Ә аннан соң нәрсә?», — дип сорадым. Ул: ***«Ата-анага игелекле булу»,*** — диде. Мин: «Ә моннан соң нәрсә?», — дип сорадым. Ул: ***«Аллаһ юлында җиһәд»,*** — диде».

Гомәр бин әл-Хәттаб ؓ янына берәү килә дә: «Минем олы яшькә ирешкән әнием бар, хәтта ул үзенең тышка чыгу йомышын да үти алмый һәм минем аркам аның өчен атланып йөри торган ат кебек, мин анам каршында булган бурычымны үтәдемме?», — дип сорый. Гомәр ؓ аңа: «Юк! Чөнки ул сине кечкенә вакытыңда күтәреп йөргәндә, синең киләчәктә үсеп, яшәвеңне өмет идә иде, ә син аны күтәреп йөргәндә, киләчәктә аның бу дөньяны ташлап китүен өмет итеп күтәрәсең», — диде.

Гали бин әл-Хәсәнгә: «Син бик тә игелекле кешесең, ләкин ни өчен син әниең белән бергә бер савыттан ашамыйсың?», — дип соралгач, ул: «Мин аның белән ашаганда, әниемнең күзе төшкән ризыкка минем кулым алданрак төшәр дип куркам һәм шулай итеп аны рәнҗетермен дип уйлыйм», — дип җавап бирде.

Мөхәммәд бин Сирин үзенең әнисе белән, явыз патшадан кешеләр ничек куркып вә аңа ялагайланып кына сөйләшә торган булсалар, ул да (әнисе белән) шулай сөйләшә иде.

## 🕮 Хатының каршында булган ятак бурычын үтә!

(وَلَهُنَّ مِثْلُ الَّذِي عَلَيْهِنَّ بِالْمَعْرُوفِ) البقرة: ٢٢٨

Мәгънәсе: **«Хатыннарның ирләре каршында бурычлары булган кебек, шундый ук хокуклары да бар».**

Синең, хатының белән ләззәтләнү хокукың булган кебек, аның да синең белән ләззәтләнүдә шундый ук хокуклары бар, һәм үзеңне якынлык кылу савабыннан мәхрүм итмә! Чөнки сиңа, хатының белән якынлык кылуда әҗер-савап бар.

قَالَ النَّبِيُّ صلى الله عليه وسلم: «...وَفِى بُضْعِ أَحَدِكُمْ صَدَقَةٌ» قَالُوا: يَا رَسُولَ اللَّهِ أَيَأتِى أَحَدُنَا شَهْوَتَهُ وَيَكُونُ لَهُ فِيهَا أَجْرٌ؟ قَالَ: «أَرَأَيْتُمْ لَوْ وَضَعَهَا فِى حَرَامٍ أَكَانَ عَلَيْهِ فِيهَا وِزْرٌ؟ فَكَذَلِكَ إِذَا وَضَعَهَا فِى الْحَلاَلِ كَانَ لَهُ أَجْرٌ»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сезнең якынлык кылуыгыз да — садака.*** Сорадылар: «Йә расүл Аллаһ! Без үзебезнең җенси шәһвәтебезне үтәгән өчен дә әҗер-савап буламыни?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә ул кеше шәһвәтен хәрамга (чит, хәрам хатынга) кулланса, аңа гөнаһ була түгелмени? Шулай ук, әгәр дә ул шәһвәтен хәләлгә кулланса, аңа әҗер-савап була»[58].***

***Әсәр:*** Бервакыт хәлиф Гомәр бин әл-Хәттаб 🙧 янына бер хатын килде дә: «Әй мәэминнәрнең әмире! Минем ирем көннәр буе ураза тота һәм төннәр буе намаз укый. Мин аннан зарланырга теләмим, чөнки ул Аллаһка итагать итүдә», — диде. Гомәр ﷺ аңа: «Ирен мактаучы хатынга Аллаһ әҗер-савабын бирсен», — дип җавап бирде. Бу хатын сүзләрен Гомәргә 🙧 берничә тапкыр кабатлады, әмма ләкин Гомәр аның һәр кабатлавына да шулай ук җавап бирде. Бу вакытта алар янында Кәгъб бин Сүр әл-Әсәди дә бар иде, һәм ул эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алып, Гомәргә: «Әй мөэминнәрнең әмире! Бу хатын белән ире арасын хөкем ит!», — диде. Гомәр 🙧 Кәгъбтән: «Ул хөкем турында сорадымени?», — дип сорады. Кәгъб: «Бу хатын сиңа, иренең ятактан читләшкәнлеге хакында зарлана

58 Мүслим (1006)

һәм ятактагы үзенең хокукын таләп итә», — диде. Гомәр رضي الله عنه Кәгъбкә: «Син моны аңлагансың икән, үзең үк араларын хөкем ит!», — диде. Кәгъб хатынның ирен китерергә кушты, ире килгәч ул аңа: «Синең хатының синнән зарлана», — диде. Бу ир: «Мин әллә аны матди яктан тәэмин итүдә рәнҗетәмме?», — дип сорады. Кәгъб: «Юк», — диде. Хатыны: «Ирем минем ятагымнан бүленеп, вакытын гыйбадәттә генә үткәрә. Мин аны хатыны мәсьәләсендә мактый алмыйм», — диде. Шуннан соң Кәгъб бу иргә: «Аллаһ дүрт хатын алырга рөхсәт итте, ә синең бер хатын, шулай булгач, өч көнеңне син гыйбадәттә үткәр, ә инде бер көн вә бер төн — хатыныңныкы, аның хакын үтә!», — дип хөкем чыгарды. Гомәр رضي الله عنه Кәгъбкә: «Әй Кәгъб! Мин инде белмим дә, синең бу хатынның зарын аңлавыңнан сиңа сокланыйммы, әллә алар арасын шулай хикмәт белән хөкем итүеңнән сокланыйммы! Мин сине бүгеннән үк Басра шәһәренә казый итеп билгелим», — диде[59].

## Якынлык кылганда балаларыңнан читләш!

Якынлык кылу — ул яшерен вә сер булырга тиеш, шуның өчен дә аны балаларың күрмәслек булсын!

Бервакыт Мүгавия бин Хәйдәһ رضي الله عنه пәйгамбәребездән ﷺ: «Йә расүл Аллаһ! Гауратләребезне кемгә күрсәтергә ярый һәм кемгә ярамый?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ аңа: ***«Хатыныңнан һәм кул астыңда булган кәнизәктән[60] башка, барчасыннан да гауратеңне сакла!»,*** — диде[61].

Ә инде: ***«Әгәр дә хатының белән якынлык кылырга теләсәң, яшерен[62]»,*** — дигән хәдисне шәйх Әлбәни зәгыйфь диде.

Габдуллаһ бин Гомәр رضي الله عنه әгәр дә якынлык кылырга теләсә, бүлмәдән хәтта күкрәк баласын да чыгарып куя торган иде.

59 «Мүсаннаф» Габдурраззак
60 Кол хатын-кыз
61 Әбү Дауыд (4017) хәсән
62 Ибен Мәҗәһ (1921)

## 🕮 Хатының хайд[63] вакытында һәм арт әгъзасына якынлык кылудан саклан!

Хайд вакытында һәм арт әгъзага якынлык кылу — хәрам, шуңа да бик тә сак бул! Мондый гөнаһлар йөрәкне каралта, йөзне пычрата һәм башка гөнаһларга юл ача.

(وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الْمَحِيضِ قُلْ هُوَ أَذًى فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ
وَلَا تَقْرَبُوهُنَّ حَتَّى يَطْهُرْنَ فَإِذَا تَطَهَّرْنَ فَأْتُوهُنَّ مِنْ حَيْثُ أَمَرَكُمُ
اللهُ إِنَّ اللهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ) البقرة: ٢٢٢

Мәгънәсе: **«Янә синнән хатыннарның күрем каны хакында сорыйлар. Әйт: «Ул (күрем каны) иза чиктерә (азаплый, интектерә)», — дип. Күремле вакытларында, күремнәре бетеп пакьләнгәннәренә чаклы хатыннарыгыздан киселеп торыгыз (якынлашмагыз). Күремнәреннән пакьләнсәләр, Аллаһ әмер иткән урыннан якынлык кылыгыз. Дөреслектә, Аллаһ тәүбә итеп төзәлүчеләрне, һәм күңел вә тән нәҗесләреннән пакьләнүчеләрне сөя».**

(نِسَاؤُكُمْ حَرْثٌ لَكُمْ فَأْتُوا حَرْثَكُمْ أَنَّى شِئْتُمْ) البقرة: ٢٢٣

Мәгънәсе: **«Хатыннарыгыз сезгә игенлек вә чәчүлек урыны, үзегез теләгән яктан вә теләгән вакытта игенлекләрегезгә килегез!».**

Хатыннарның игенлек вә чәчүлек урыны — балага узу әгъзасы, шулай булгач, ошбу әгъзага гына якынлык кылырга ярый.

Арт әгъзага якынлык кылудан сакланырга кушып, расүлебез ﷺ бик күп хәдисләрендә кисәтеп узды.

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ رضي الله عنه قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللهِ صلى الله عليه وسلم: «مَلْعُونٌ مَنْ أَتَى امْرَأَتَهُ فِى دُبُرِهَا»

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ؓ: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хатынының арт әгъзасына якынлык кылучы — мәлгунь (ләгънәт кылынды)»[64].***

---

63 Хатын-кызның айлык күрем каны

64 Әбү Дауыд (2162 хәсән)

عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ قَالَ قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم: «مَنْ أَتَى حَائِضًا أَوِ امْرَأَةً فِى دُبُرِهَا أَوْ كَاهِنًا فَصَدَّقَهُ بِمَا يَقُولُ فَقَدْ كَفَرَ بِمَا أُنْزِلَ عَلَى مُحَمَّدٍ»

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем дә кем хатыны хайд вакытында якынлык кыла икән яки аның арт әгъзасына якынлык кыла икән, яки күрәзәчегә барып аның сөйләгәннәрен раслый вә ышана икән, ул Мөхәммәдкә ﷺ иңгән Коръәнгә (дингә) көферлек кылган була»[65].***

## 🕮 Хатыныңны талак кылуда ашыкма!

Күңелеңә хуш килмәгән һәрбер нәрсәдән сәбәп табып, хатыныңа талак бирергә һәм шәйтанны шатландырырга ашыкма!

(وَعَاشِرُوهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ فَإِنْ كَرِهْتُمُوهُنَّ فَعَسَى أَنْ تَكْرَهُوا شَيْئًا وَيَجْعَلَ اللَّهُ فِيهِ خَيْرًا كَثِيرًا) النساء: ١٩

Мәгънәсе: **«Никахыгызда булган хатыннар белән яхшы мөгамәләдә булыгыз, гәрчә аларны бик яратмасагыз да, өметледер, сез яратмаган нәрсәдә Аллаһның күп яхшылык кылмаклыгы».**

Талак Иблискә иң сөйкемле гамәлләрнең берсе булып тора. Пәйгамбәребез ﷺ бу хакта үзенең хәдисендә болай диде:

عَنْ جَابِرٍ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «إِنَّ إِبْلِيسَ يَضَعُ عَرْشَهُ عَلَى الْمَاءِ ثُمَّ يَبْعَثُ سَرَايَاهُ فَأَدْنَاهُمْ مِنْهُ مَنْزِلَةً أَعْظَمُهُمْ فِتْنَةً يَجِيءُ أَحَدُهُمْ فَيَقُولُ فَعَلْتُ كَذَا وَكَذَا فَيَقُولُ مَا صَنَعْتَ شَيْئًا قَالَ ثُمَّ يَجِيءُ أَحَدُهُمْ فَيَقُولُ مَا تَرَكْتُهُ حَتَّى فَرَّقْتُ بَيْنَهُ وَبَيْنَ امْرَأَتِهِ قَالَ فَيُدْنِيهِ مِنْهُ وَيَقُولُ نِعْمَ أَنْتَ»

Мәгънәсе: Җәбирдән ﵁: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иблис гарешен диңгезгә куйгач (иблиснең мәркәзе — диңгез), фәсәд таратыр өчен үзенең төркемнәрен җирнең төрле ягына җибәрә. Иң зур фетнә ясаучы шәйтан — аның иң якыны була. Шуларның берсе аның янына килә дә:***

65 Ибен Мәҗәһ (639 сахих)

***«Мин шундый-шундый бозыклык ясадым», — ди. Иблис аңа: «Син һичнәрсә дә эшләмәдең», — дип, аны инкяр итә. Шуннан соң икенче берсе килә һәм: «Мин ир белән хатын арасына фетнә салдым, вә аларның араларын аерганчыга кадәр фетнә салуны ташламадым», — ди. Иблис аны үзенә якынрак ала һәм аңа: «Син иң яхшы эш эшләдең», — ди»[66].***

Талак, никах белән билгеләнгән файдаларны җимерә. Шул сәбәпле балаларның ата-ана иркәсеннән мәхрүм калулары дисеңме, мөселманнар арасында низаг вә фетнә чыгуы дисеңме һәм башкалар. Шулай ук әйткәнебезчә, талак шәйтанны сөендерә, ә Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде, мәгънәсе: **«Әй Мөхәммәд! Колларыма әйт, бер-берсе белән яхшы сүзләр илә сөйләшсеннәр! Хакыйкатьтә, шәйтан аларның арасына ихтиләф вә низагны сала. Әлбәттә, шәйтан кешеләргә ачык дошман булды».** («әл-Исра» 53) Һәм дә талакка караганда килешү вә бергә булу хәерлерәк дип болай әйтте, мәгънәсе: **«Килешү, гафу итешү — аерылышудан хәерлерәк».**( «әл-Ниса» 128)

66 Мүслим (2167)

# Йомгаклау

Әлхәмдүлилләһ, Аллаһның теләге вә ярдәме илә изге гамәлләр тәмамлана.

Без инде шушында китабыбызның беренче өлешен тәмамлыйбыз. Китапның икенче өлеше «Ир белән мөгамәлә итү серләре» — дип исемләнәчәк һәм Аллаһ Раббыбызның теләге белән якын араларда чыгачак, иншәАллаһ.

Йә Аллаһ! Ниятләребезне ихлас кыл һәм гамәлләребезне кабул ит! Безгә изге вә салиха хатыннар бир, араларыбызга өлфәт мәхәббәт сал һәм дә игелекле балалар белән ризыкландыр!

Хакыйкатьтә, Син ишетүче вә догаларны кабул итүчесең!

## Эчтәлек

Кереш сүз.....................................................................3
Хатыныңны ничек сайлыйсың?........................................8
Хатының өчен бизән вә зиннәтлән!...............................9
Хатыныңның туганнарына ихтирамлы бул!.................10
Хатыныңа елмаеп кара!................................................11
Хатыныңа иң матур исемнәр белән дәш!....................11
Сезнең иң хәерлегез — гаиләсенә иң хәерле булганы!.........................................................................................12
Хатыныңа ярдәм ит!.......................................................14
Хатыннарың белән күңелле бул һәм уйна!..................15
Хатыныңа матур сүзләр әйт һәм макта!......................17
Хатыныңа бүләкләр бир!...............................................18
Йорт әһелләреңне шәргый бәйрәмнәр белән котла һәм шатландыр!..................................................................................18
Хатыныңны назла вә иркәлә!.......................................19
Хатыныңда артык шикләнүдән саклан!.......................20
Хатының белән ягымлы сөйләш һәм битәрләмә!.......20
Хатының каршында булган бурычларыңны онытма!..22
Хатыныңның кимчелекләрен яшер!............................23
Хатыныңа сөйкемле вә мөлаем бул!...........................23
Хатының белән киңәшләш!..........................................23
Хатыныңнан гаеп эзләмә!.............................................24
Хатыныңны юат!............................................................25
Гаиләң сине гыйбадәттән читләштермәсен!..............27
Хатыннарың арасында гадел бул!..............................27
Хатыныңның холкын көч белән үзгәртәм димә!..........28
Хатыныңа кул күтәрмә!.................................................30
Хатыныңны гыйлемгә өйрәт!.......................................30
Хатыныңны ата-анаңнан артык күрмә!......................31

🕮 Хатының каршында булган ятак бурычын үтә!............32
🕮 Якынлык кылганда балаларыңнан читләш!.................34
🕮 Хатының хайд вакытында һәм арт әгъзасына якынлык кылудан саклан!...........................................................................34
🕮 Хатыныңны талак кылуда ашыкма!.............................36
Йомгаклау.............................................................................38